**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Карамалы авылы №24 19 февраль 2016 ел.

Карамалы авылы җирлеге Советының
2016 елның 16 февралендә 23 номерлы
үзарасалым җыю һәм куллану
буенча җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турындагы
карарына үзгәрешләр кертү

Карамалы авыл җирлеге җыелган үзарасалымны куллану юнәлешен ачыклау максатыннан:

Карамалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте**:**

1. Карамалы авылы җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча, җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турындагы №23 2016 елның 16 февралендә кабул иткән карарының 2 пунктындагы 2 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләр кертү:

2.Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү өчен (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарга һәм йортларга урам исемнәре һәм йорт номерлары урнаштыруны, кечкенә архитектура формалары кую һәм карап торуны кертеп): 80 мең су

- юлларны кардан чистарту:
  Карамалы авылы-15 мең сум
  Таллы-Бүләк авылы- 5 мең сум
  Октябрь-Бүләк авылы-10 мең сум
- Карамалы мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндерү- 50 мең сум”

Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru түбәндәге веб адрес буенча урнаштырыла.

Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис А.Р.Ногманов